**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 4 июнендәге 1657 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының 2014 елның 4 мартындагы 1281 номерлы «Казан шәһәре муниципаль берәмлегендә урам исемнәре һәм йорт номерлары күрсәткечләрен рәсмиләштерүне һәм урнаштыруны җайга сала торган нигезләмәне раслау турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында**

1991 елның 25 октябрендәге 1807-1 номерлы «Россия Федерациясе халыкларының телләре турында»гы Россия Федерациясе Законының 23 статьясына, 1992 елның 8 июлендәге 1560-XII номерлы «Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында»гы Татарстан Республикасы Законына таянып, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 19 ноябрендәге 1221 номерлы «Адреслар бирү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару кагыйдәләрен раслау турында»гы карары нигезендә, күрсәткечләр рәсмиләштерү эшен камилләштерү максатыннан **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2014 елның 4 мартындагы 1281 номерлы карары белән расланган Казан шәһәре муниципаль берәмлегендә урам исемнәре һәм йорт номерлары күрсәткечләрен рәсмиләштерүне һәм урнаштыруны җайга сала торган нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.1.2 пунктчаны түбәндәге редакциядә бирергә:

«1.1.2. Тарихи үзәктә урнашкан, әлеге нигезләмәнең 1.1.1 пунктчасында күрсәтелгән күрсәткечләр урнаштырыла торган урамнардан тыш (5 номерлы кушымта), Казан шәһәренең шәһәр мохите эстетикасына таләпләр югары булган урамнарында (2 номерлы кушымта) урам исеме һәм йорт номеры өч телдә (Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә (татар, рус) һәм инглиз телендә) язылган яктыртылган күрсәткечләр (3, 4 номерлы кушымталар) урнаштырыла»;

1.2. 1.1.3 пунктчаны түбәндәге редакциядә бирергә:

«1.1.3. Казан шәһәренең барлык урамнарында да урам исеме һәм йорт номеры Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә (татарча, русча) язылган күрсәткечләр урнаштырыла (6-9 номерлы кушымталар)»;

1.3. 3.4 пунктчаны түбәндәге редакциядә бирергә:

«3.4. Тарихи үзәктә һәм шәһәр мохите эстетикасына таләпләр югары булган урамнарда куела торган адрес атрибутикасына Казан шәһәре Башкарма комитетының Торак-коммуналь хуҗалык комитеты белән килештерелгән паспорт (приложения №10-11) төзелә».

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.Ә.Гыйниятуллинга йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**